Республика Татарстан
**ГЛАВА МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ПОСЕЛОК ГОРОДСКОГО ТИПА ДЖАЛИЛЬ» САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
ул.Ахмадиева, д.26, п.Джалиль, 423368
Телефон: (85559) 31-0-97, 60-2-20, факс: 31-0-97
E-mail: POSSOVETD@mail.ru

Татарстан Республикасы
**САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ «ҖӘЛИЛ ШӘҺӘР ТИБЫНДАГЫ ПОСЕЛОК» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**
Ахмадиев урамы, 26 йорт, Җәлил поселогы, 423368
Телефон: (85559) 31-0-97, 60-2-20, факс: 31-0-97
E-mail: POSSOVETD@mail.ru

ОГРН 1021601312501 ИНН/КПП 1636001410/163601001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**14.11.2025 ел** **№2**

2026 елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм кулану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Кызыл Бакча торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы»муниципаль берәмлеге башлыгы карар чыгарды:

1. 28.11.2025 елның 15.00 сәгатькә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Кызыл Бакча авылы, Кызыл Бакча урамы, 18 йорт адресы буенча урнашкан торак йорт янында 2026 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Кызыл Бакча торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2026 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Кызыл Бакча территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган, I һәм II төркем инвалидларыннан, өлкән яшьтәге гражданнардан (80 яшьтән өлкәнрәк), җирлек территориясендә ел дәвамында яшәүче гражданнардан, авыр тормыш хәлендә калган гаилә әгъзаларыннан тыш, РФ Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизацияне игълан итү турында» 21.09.2022 № 647 Указы буенча мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, СВОда катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме?:

1) ремонт, коймалар кору, традицион Күмү урыннарын төзекләндерү (Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Кызыл Бакча торак пункты зираты территориясен төзекләндерү (үлән чаптыру, биек агачларны йоклату һәм агач төпләрен кисү, чүп-чарны җыю һәм чыгару (килешү буенча эш өчен түләү));

2) традицион Күмү урыннарын ремонтлау, киртәләр кору, төзекләндерү (Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Кызыл Бакча торак пункты зираты территориясен ремонтлау һәм төзекләндерү эшләрен башкару өчен инструмент һәм инвентарь сатып алу);

«РИЗА» ««КАРШЫ?»

3. Әлеге карарны «пгтДжалиль» муниципаль берәмлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (http://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгән көннән алып җиде көн дәвамында.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы»
«Җәлил шәһәр тибындагы поселогы»
муниципаль берәмлеге башлыгы Р. Ә. Каримов